ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ШУМКОВСКОГОСЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
РЫБНО-СЛОБОДСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

422653, с.Шумково,
ул.Центральная, дом 4

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛЫК БИСТӘСЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ШУМКОВО АВЫЛ ЖИРЛЕГЕНЕҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

422653, Шумково,
Узэк урамы, 4 нче йорт,

Тел.: (84361) 26332, факс: (84361) 26332, e-mail:smk.rs@tatar.ru сайт: ribnaya-sloboda.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

22.01.2024 Шумково авылы № 2

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шумково авыл җирлегендә җирләү (мәет кую) буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «җирләү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясындагы 3 пункты һәм 12 статьясындагы 3 пункты (үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне исәпкә алып), Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы карары, Татарстан Республикасында җирләү һәм җирләү эше турында» 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары турында документларга нигезләнеп Карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шумково авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 1 нче кушымта һәм әлеге карарның 2 нче кушымтасы нигезендә 8370,20 сум күләмендә билгеләргә һәм 2024 елның 1 февраленнән гамәлгә кертергә.
2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шумково авыл җирлеге Башкарма комитетының “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шумково авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге буенча күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында” 2023 елның 31 гыйнварындагы 1 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.
3. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”ында урнаштырырга.
4. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Шумково авыл җирлеге башлыгы
вазыйфаларын үтәүче А.Р. Гилазиева

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
районы Шумково авыл җирлеге Башкарма
комитетының 2024 елның 22 гыйнварындагы
2 номерлы карарына кушымта

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы Шумково авыл җирлегендә
2024 елның 1 февраленнән җирләү (мәет кую) буенча хезмәтләрнең
гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган
хезмәтләрнең бәясе (хакы)

| Хезмәтләрнең аталышы | Хезмәтләрнең бәясе (хакы) (сумнарда) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,0 |
| 2. Табутны һәм җирләү өчен зарури башка әйберләрне бирү һәм китерү | 5929,46 |
| 3. Мәетне (мәрхүмнең җәсәден) зиратка (крематорийга) күчерү (алып бару) | 841,19 |
| 4. Җирләү (мәетне яндыру, соңыннан көле салынган урнаны бирү белән) | 1599,55 |
| Җәмгысе: | 8370,20 |

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
районы Шумково авыл җирлеге Башкарма
комитетының 2024 елның 22
гыйнварындагы 2 номерлы карарына
кушымта

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы Шумково авыл җирлегендә
2024 елның 1 февраленнән җирләү (мәет кую) буенча хезмәтләрнең
гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган
хезмәтләрнең бәясе (хакы)

| Хезмәтләрнең аталышы | Хезмәтләрнең бәясе (хакы) (сумнарда) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,0 |
| 2. Мәетне кәфенләү | 2963,06 |
| 3. Табутны һәм җирләү өчен зарури башка әйберләрне бирү һәм китерү | 2963,06 |
| 4. Мәетне (мәрхүмнең җәсәден) зиратка күчерү (алып бару) | 836,22 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 1607,86 |
| Җәмгысе: | 8370,20 |